


Мордовия Республикасы Матбугат үзәгендә регионыбызда эпидемиологик хәлне ачыклаган пресс-конференция үтте. Чарада Республика Мордовия Правительство Председателе урынбасары Галина Алексеевна Лотванова, Мордовия Республикасы здравохранение министры Олег Валентинович Маркин, Федеральная служба по надзору в сфере защиты прав потребителей и благополучия человека по Республике Мордовия идарәсе житәкчесе Татьяна Петровна Харитонова катнаштылар. Коронавирус йогышы белән бәйле региондагы эпидемиологик хәл мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Республика Мордовия Правительство Председателе урынбасары Галина Алексеевна Лотванова хәбәр иткәнчә, бу конгә булган мәгълүматларга караганда, РФ территориясеннән читтә - ОАЭ, Тайланд, Торкия, Вьетнам, Куба, Казахстан, Украина, Армения, Франция, Марокко, Германия, Шри-Ланка һәм башка илләрдә туристик юлламалар буенча Мордовиядән дә кешеләр булган. “Хормәтле респуб лика халкы, чит илләрдән килүчеләр, медицина оешмаларынын кайчан шалтыратуларын котеп тормыйча, үзләре турында мәҗбүри рәвештә хәбәр итәргә һәм, хәлләренә карамастан, ой карантинында булырга, барлык таләпләрне үтәргә тиеш”,- дип белдерде Галина Алексеевна. Ул ассызыклаганча, чит илләрдән кайтучылар очен кабул ителгән барлык чикләү чараларын үтәү – гражданнарнын аны гына түгел, Мордовия халкынын иминлеге мәсьәләләре дә. “Бүгенге кондә республикада эпидемиологик хәл идарәле - управляемая һәм борчу тудырмый. - Безнен алдынгы ашыгыч медицина ярдәме станциясе һәм Республика йогышлы авырулар хастаханәсе, кирәк очракта ул йогышлы госпиталь режимында эшләячәк, - диде Г.А.Лотванова. - Республикада хәл яхшы булуга карамастан, без коронавирус инфекциясе таралуга бәйле рәвештә башка илләрдә үсеш ала торган хәлләргә юл куймас очен, медицина оешмаларын әзерлибез. Мордовия Республикасы бюджетыннан дәвалау учреждениеләрендә медицина хезмәткәрләренен куркынычсызлыгын тәэмин итү очен остәмә акча бүлеп бирелгән”.
Мордовия Сәламәтлек саклау министры Олег Валентинович Маркин хәзерге вакытта республиканын дәвалау учреждениеләре теләсә нинди хәлгә әзер, дип билгеләп үтте. “Без медицина учреждениеләре структурасы эчендә берничә торле оештыру чаралары уздырабыз. Шуны билгеләп үтәм, гражданнарыбызнын сәламәтлеген сак лау очен барысын да эшлибез. Бүгенге кондә коронавирус йогышы профиле буенча шогыльләнүче топ дәвалау оешмалары - ашыгыч медицина ярдәме станциясе һәм 210 койка булган Республика йогышлы авырулар (инфекционная) хастаханәсе. Коронавирус буенча

йогышлы стационар эшен тәэмин итv очен, безгә медицина буенча башка профильләрне башка дәвалау учреждениеләренә таратырга туры килде. Бу эпидемиягә каршы вәзгыять кысаларында эшләнә. Без, хастаханәдән тыш пневмония һәм сулыш системасынын коронавирус этиологиясе булмаган башка авырулары булган гражданнарны дәвалау очен, 4нче шәһәр клиник хастаханәсенен аерым терапия корпусын ачабыз. Моннан тыш, Рузаевка район хастаханәсен резерв йогышлы госпиталь буларак жәелдерәбез; кирәк булганда, коронавирус инфекциясе һәм пневмонияле, шулай ук башка соматик патологияле пациентларга ярдәм кvрсәтеләчәк. Рузаевканын бала тудыру Йорты шулай ук коронавирус йогышы булган пациентларны кабул итv очен резерв блогы итеп vзгәртелде. Барлыгы Рузаевкада авырулар очен 240 койка әзер. Шул ук вакытта Рузаевкада яшәvчеләргә тулы кvләмдә медицина ярдәме кvрсә теләчәк. Кирәк булса, теләсә кайсы район больницаларында инфекцион койкалар ачылачак. Аерым инфекцион корпус Старошайгово больницацында бар, ә инфекцион койкаларны Ковылкино, Чамзинка, Краснослободск район больницаларында; Мордовиядә барлыгы, кирәк чакта, коронавирус инфекциясен йоктыручыларга 1206 коека булдыра алабыз", - дип ишеттерде.

Тагы ул: "Олкән яшьтәге кешеләргә морәжәгать итәм: шәһәр буенча хәрәкәт итvне чикләгез, ойдә булыгыз. Кирәк булган очракта, медицина хезмәткәрләре сезгә урыннарда ярдәм кvрсәтәчәкләр, - дип белдерде Олег Валентинович Маркин. - Моннан тыш, сезгә социаль хезмәткәрләр һәм волонтерлар ярдәм итәчәк".

Яна куркыныч авыру - коронавирус инфекциясе  таралуга, шулай ук медикларнын чит илгә чыгу куркынычсызлыгы турында берничә тапкыр кисәтvләренә карамастан, Мордовия халкы Ватаннан читкә чыгуларын дәвам итә. Федеральная служба по надзору в сфере защиты прав потребителей и благополучия человека по Республике Мордовия идарәсе житәкчесе Татьяна Петровна Харитонова мәгълvматларына караганда, кон саен регионга 60-100 кеше кайта. Чит илдән кайтучыларга 14 конгә хастаханә кәгазе - больничный лист бирелә, дип анлатты ул. Кешенен ОРВИ клиникасы булса, Республика клиник хастаханәсенә озатыла. Шулай ук Татьяна Петровна коронавирус инфекциясен профилактикалау буенча топ чаралар турында искә тошерде: чит илгә барудан тыелырга; жәмәгать урыннарына бармаска; ОРВИ билгеләре булган кешеләр белән якын элемтәдә һәм бер бинада булмаска; кулларны ешрак сабын һәм су белән юарга; гаджетларны, оргтехниканы дезинфекцияләргә; сәламләгәндә кочмаска һәм кул алышмаска; шәхси гигиена предметларыннан гына файдаланырга.

Наилә НАСЫРОВА